**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге**
**Советы**

422750, Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 1
Тел,факс 884369 2-15-68

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеатнинского сельского поселения**

422750, Атнинский муниципальный район
с.Большая Атня,
ул. Советская, 1
тел, факс .884369 2-15-68

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

«07» ноябрь 2022 ел.

№ 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Җөлби авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2022 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Җөлби авылында үзара салым кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлегенең Яңа Җөлби авылында үзара салым кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты;
– халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 19 ноябре, 09.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны-Яңа Җөлби авылы, Үзәк урамы, 12А йорт янында.

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итү:

- 2022 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегендә Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 нче йорт адресы буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә;
- сайлау хокукына ия булган яңа Җөлби авылы халкы исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Яңа Җөлби авылы халкына мәгълүмати стендлар һәм башка ысуллар аша халык җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Яңа Җөлби авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк

гражданнардан, 1 төркем инвалидлар, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм аларнын гаилә әгъзаларынан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкару:

1) Яңа Җөлби авылы Үзәк һәм Киров урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

2) Үзәк урамы буенча Яңа Җөлби авылы урам юлларын ремонтлау һәм капламалар урнаштыру (вак таш сатып алу, ремонт һәм җәю буенча хезмәтләр өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://atnya.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Яңа Җөлби авылы, Үзәк урамы, һәм Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан административ бинада урнашкан мәгълүмат стендларында да.
4. Әлеге карар аны игълан иткән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Хакимов